

АФАНАСИЙ ПРОКОФЬЕВИЧ ЩАПОВ

# АФАНАСИЙ ПРОКОФЬЕВИЧ ЩАПОВ

Атаклы тарих галиме, фикер иясе һәм үзенчәлекле талант булган Афанасий Прокофьевич Щапов — XIX йөзнең 60—70 нче елларындагы рус җәмгыятендә якты һәм оригиналь бер фигура булып күтәрелде. Анар карата Плеханов: „Щаповның тормышында өйрәнерлек яклар шундый күп, аның турында укучыларның исләренә тагын бер кат төшереп үтү һәм аны официаль галимнәребезнең „тыныч тормыш“ларына каршы кую бер дә комачауламас иде“ дигән фикерләрне язды.

А. П. Щаповның самодержавие изүе астында шундый тиз өзелгән җәмагәтчелек эшчәнлегенең иң якты өлеше — аның Казанда яшәгән чагына туры килә.

1.

А. П. Щапов — Иркутск губернасында, Лена елгасының бер тармагы буенда, тайгада урнашкан Анга исемле авылда, крестьяннән чыккан ярлы дьяк семьясендә туа. Аның анасы бурәт кызы була. Щапов соңыннан үзенең чыгышы крестьяннән булуын аеруча басым ясап әйтә. Щаповларның зур семьясе ярым ач тормыш кичерә.

Улына белем бирү турында уйлап йөргән атасы аны үсә төшү белән бурсага (руханилар хәзерләүче ябык мәктәпкә) урнаштыра. Ул вакытта Консистория руханиларның балаларын „Казна исәбе“нә укыткан. Ләкин бу „Казна исәбе“ — бурсада укучылар өчен ачтан үлмәслек кенә мөмкинлек биргән. Щапов соңыннан „Бурсаклык тормышыннан“ исемле мәкаләсендә — үзе укыган чактагы авырлыкларны, бурсадагы

коточкыч пычыраклыкны, ач яшәүне, төрле чирләр белән газаплануны, аңлап уку урнына күңелдән бикләүне, розгаларны һәм карцерны — искә алып яза.

Бурсада алты ел вакыт үткәргәч, Щапов бераз яхшырак шартлы, ләкин розга белән суктыру тәртибе сакланган, духовная семинариягә күчә. Семинариядә күбесенчә дин-чиркәү сабаклары гына өйрәтәләр. Бу сабаклар, сан ягыннан күп булсалар да, реаль белемне бик аз бирәләр. Дини булмаган китаплар уку һәм семинариядән тыш багланышта булу бик нык тыела. Дисциплинаны бозган өчен яки солдатка озаталар яки податное сословиегә язу өчен губерна правлениесенә җибәрәләр. Семинария башлыгы тарафыннан „яраксыз булганнарны семинария ишек алдыннан себерке белән кудырту" турында боерык бирү хәлләре дә булгалаган. Хәтта гаепләнгән семинаристны махсус церемония ясап кууга хәтле барып җиткәннәр. Моның шикелле „тәрбия" — холыкларны тупасландырган, дөньяга карашны тарайткан һәм семинаристлар шуның аркасында эчкечелеккә бирелеп үзләренең ризасызлык тойгыларын аракы белән басарга мәҗбүр булганнар.

1852 нче елны семинарияне тәмам иткәч, А. П. Щаповны казна исәбенә Казандагы духовная академиягә укырга җибәрәләр. Щаповның бу еллары турында аның замандашы Шашков болай дип яза: „Ул бик юаш, тартынучан табигатле булып, аракы эчмәүче, трубка тартмаучы, хатын-кызны һәм бернинди дә күңел ачуларны белмәүче буйдак булып үсте".

Казандагы духовная академия рекацион монахлык мәктәбе булып корылган иде. Аның ректоры коридорга чыгып, йокы бүлмәләренә кереп, студентлар артыннан күзәтү алып бара һәм үсеп ир булган кешеләргә карата (духовная академиядә утыз яшьлек студентлар да укыйлар) ач тоту, иртәнге һәм кичке гыйбадәт вакытларында тезләндереп кую кебек җәзалар куллана. Дин тотуда тырышлык күрсәтүчеләр һәм начальникларның сүзен тыңлаучылар, аларга баш иючеләр генә мактау ишетәләр иде.

Академиядә шул ук семинария сабакларын тагын да киңәйтә төшеп һәм... тагын да баш ваткычрак итеп өйрәтәләр. Көнчыгыш „инородецлары" арасында православие дине таратучы миссионерлар хәзерләүче

бу академиядән барлык „дөнья" фәннәрен куалар. Ректорның үз әйтүе буенча — „дөнья" әдәбияты — „ифрат киң чүл" булып исәпләнә. „Шикле кеше"гә әйләнү өчен студентка Гоголь, Пушкин китаплары белән, яки „Отечественные записки" томнары белән күренү җитә кала. Академиянең иң әшәке бер ягы булып шундый „оригиналь" гадәт урнашкан була: либеральлек өчен яки ректорның кирелеге белән профессорларны бер предметтан икенчене укытырга күчерәләр. Ректор үзенә ошамаган лекцияләрнең эчтәлеген үзгәрттерергә дә үзен хаклы дип саный. Нәтиҗәдә академиядән иң җанлы, иң талантлы кешеләр качып бетәләр.

А. П. Щаповның замандаш биографлары аның студентлык чагын, аның формалашу вактын болай дип тасвирлилар: — „Афанасий Прокофьевич начальникларның сорауларын семинариядәге шикелле үк үтәвендә дәвам итте. Ул үзенең гадәте буенча — һаман да дәресләргә күмелгән һәм тормыш белән һичбер таныш булмаган, җәмагатьчелек интересларыннан читләшкән аскет, тирә-юньдәге хәлләргә һич тә исе китмәстән, ул тәүлегенә унҗидешәр сәгатьләп китап өстендә эшли. Аның белеме үсә, фән китапларыннан күчереп алган язулары күбәя баралар, тик әле анарда аныкланган характер юк һәм дөньяга билгеле бер караш урнашмаган. Анарда кер тимәгән һәм һичбер төрле компромисска күнмәүчән, саф, ялкынлы йөрәк бар да, халыкка ниндидер бер романтик мәхәббәт бар. Аның күзен ачу өчен бер этәргеч кенә кирәк һәм ул үзенә нинди генә зур куркыныч янап торса да, караңгылыкны нәләтләп яктылыкка табан омтылачак. Дин мәктәбенең үзенчәлекләре аркасында ул тормышка һәм кешеләргә карата үзендә тәнкыйть карашы гына эшләп чыгара алмый...

Афанасий Прокофьевич баштан ук үзенең уйларын турыдан-туры, ерымачык итеп әйтүе белән танылды: уенда нәрсә булса, телендә дә шул иде аның һәм һәр кайчан, теләсә кем алдында ул үз сүзен туры итеп әйтә, аның холыгы да самимий, яшь баланыкы төсле бер катлы, риасыз иде. Йөрәк сафлыгы аркасында ул интриганың, кара эчлелекнең, хәйләкәрлекнең нәрсә икәнен дә аңламый. Аның саф күңеллелеге тиңсез кыюлык, батырлык белән бергә тоташа. Ул

сторож белән дә, иптәше белән дә, ректор белән дә, имтихан вакытларында да бер үк төсле тонда сөйләшә, һәм аның шулай булуында үзен башкалардан аерып күрсәтү, кылану теләге юк, аның кыюлыгы — йөрәгенең сафлыгыннан, үз уена үзе ышанудан килеп чыккан сыйфат... Шул ук вакытта ул үз-үзен сөю белән дә аерылып тора, үзеннән һәм килбәтеннән һичбер нинди көлү — мыскыллауны күтәрә алмый иде. Аның килбәте һәм манералары чибәрлектән ерак торалар, чөнки ул тышкы күренешкә нәфрәт белән карый. Чамадан тыш тиз кабынып китүчән табигатле һәм иптәшләре арасында, гәрчә шул ук иптәшләре аның акылын һәм эш сөючәнлеген тиешенчә такдир итсәләр дә, үзенең кыргый характеры белән тилемсә дип әйтерлек дәрәҗәдә исәр (чудак) санала иде[1]".

Щаповның тырышлыгына барсы да сокланып караганнар. Ул тәүлек әйләнәсенә диярлек вактын контор-ка артында үткәргәнлектән, итекләре тиеп торган урыннар идәнгә батып кергәннәр. Ул урынны студентлар „яңа столпник изге Афанасий чокырлары" дип атаганнар. Ул бөтен вактын рус тарихы белән рус әдәбиятын өйрәнүгә багышлаган. Сергей Соловьев, Карамзин, Погодин, Арцыбашевлар аның һәр вакыт укып йөргән авторларыннан саналганнар. Афанасий Прокофьевич үзенең төп игтибарын рус халкының тормышына, көнкүрешенә юнәлтә. Халык һәм аның тормышы Щаповны яшьтән үк үзләренә тарталар.

Казан духовная академиясендәге төрле урыннардан җыелган студентлар укыйлар һәм алар бер-берсе белән сөйләшеп, халык тормышының төрле яклары, этнографиясе белән танышалар. Бу хәл Афанасий Прокофьевич Щапов өчен бик әһәмиятле була. Аның изелгән рус крестьяннәренә кайнар мәхәббәт саклавын белгән студентлар, каникул вакытларында эч пошканнан сүз көрәштереп, Щаповны үзлегеннән чыгару өчен крестьяннәрне яманлаган булып сөйлиләр. Бер вакытны шулай, студентлардан берсе ниндидер озын көйле ерны бик сагышлы итеп ерлый башлагач, Щапов күзләреннән яшь чыккан хәлдә бөтен бер речь сөйләп ташлаган: „Ходаем, рус йөрәгенә бикләнеп яшәү нинди куркыныч. Аңар иркенлек, һава

---

[1] Н. Я. Аристов — „А. П. Щапов".

кирәк. Калын баулар белән уралып биктә яшәгәне өчен дә рус кешесе йоклый һәм ялкаулыкка бирелә[1]".

Академиядә укыган соңгы вакытларын Щапов магистрлык степене алу өчен хәзерләгән „Рус иске обрядчеләренең расколы" исемле диссертация язу өстендә үткәрә. Ул үзенең тормышын фән эшчәнлегенә багышларга тели һәм курсны тәмам иткәч Академиядә фән эшенә калу мәсьәләсе дә шул диссертациягә бәйләнгән була. Бу диссертация начальниклар тарафыннан әерым мактауларга очрамаса да, Щапов рус тарихы кафедрасында эшләргә калдырыла.

1856 нчы елның сентябреннән башлап Щапов лекцияләр укырга керешә. Замандашларының әйтүе буенча, ул аларны җидди бер системасыз, тигезсез укый. Бу елларда аның тарихка гыйлми карашы урнашып кына бара әле һәм ул дини-клерикаль догмалар йогынтысыннан акрынлап котылып килә. Шулай булуына, соңыннан Москва университетының профессоры булып танылган, ә ул вакытта Казан университетының доценты булып эшләүче С. В. Ешевский белән якынлашу ярдәм итә. Ешевский атаклы Гранскийнең шәкерте һәм системага салынган тарихи карашлы кеше була. Ул Щаповка билгеле булмаган тарихи материалларны белә һәм бу материаллар Щаповның күзен ачалар.

1857 нче елда Ешевский Москва университетына күчә. Бу вакытта инде ныгып җиткән һәм иске чиркәү йогынтысы богауларын үзеннән алып ташлаган Щапов болай дип яза: „Устрялов һәм Карамзин тарихларын өйрәнгән чагымда миңа ул тарихларда безнең Русь авылы тормышы күренмәү, простой кара халык дип аталып йөрүче массалар тарихының күренмәве сәер тоела иде. Иң зур күпчелек булган бу массаның белем алырга, тарихи үсешкә һәм әһәмияткә хакы юкмени? Летописьләрне һәм писцевой книгаларны укып карасагыз күрерсез, Россияне төзүчеләр һәрбер урында, һәркайчан крестьяннәр булып килделәр һәм алар үзләренең көчле җилкәләрендә туган илебезнең якты киләчәген күтәреп килделәр".

---

[1] Аристов — „А. П. Щапов".

Щапов якшәмбе мәктәпләре оештыруда бик эшлекле рәвештә катнаша һәм аң-белем тарату җәмгыяте оештыру мәсьәләсен кайгыртып йөри. Аның замандашларыннан берсе шушы уңай белән болай дип яза: „Профессор Щапов авыл мәктәпләре, крестьяннәр өчен түләүсез көтепханәләр, авыл укытучылары хәзерләүче мәктәпләр оештыру аркылы халык арасында аң-белем таратучы җәмгыят төзергә тели. Рөхсәт кенә бирсеннәр, ә моның өчен кирәкле акча табылган: купецлар үз капиталларын вагдә иттеләр инде, монардан тыш крестьяннәргә җан башына 1 яки 2 тиеннән акча иганә итү турында такдим ясарга уйланыла"[1]. Озакламый, Щаповның „Рус иске обрядчеләренең расколы" исемле диссертациясенә карата Добролюбов мәкаләсе басыла. Добролюбовның аяусыз тәнкыйте Щаповның демократизм мәсьәләләрен аңламавын, аның карашларындагы каршылыкларны күрсәтүе Щаповта бик тирән тәэсир калдыра. Алдынгы кешеләр йогынтысы белән һәм үз өстендә тәнкыйтьле эш алып бару аркасында, акрынлап Щаповның дөньяга карашы ныгый һәм аның демократик карашлары тулысынча формалашалар.

1860 елның көзендә Щапов Казан университетының рус тарихы кафедрасына күтәрелә. Ул анда, башта Ешевскийнең һәм аннан соң аның урнына калган Поповның Москвага күчеп китүләре аркасында, очраклы рәвештә элә́гә. Щаповны университет советына „студентларга зур файда китерә алачак галим" дип такдим итүче дә Попов була.

Студентларда Щаповка карата, духовная академиядән килгән поп баласы дигән, алдан беркетелеп куелган фикер яши. Алар аның турында „Назареттан яхшылык көтү мөмкин түгел" дип шаяртып сөйлиләр. Ләкин, Казан университеты өчен зур вакыйга булып яңраган беренче лекциядән соң, студентлар аны кайнар дуслык тойгысы белән ярата башлыйлар. Шул лекциядә катнашкан бер студентның истәлегендә шушындый юллар язылган:

„Беренче лекциягә халык шул хәтле күп җыелды, 7 нче, зур аудиториядә тыңларга теләүчеләр өчен урын җитмәде. Залга күчеп тыңларга карар ителде. Башында

---

[1] Муравский — „Былое" — 1907 ел, № 1.

попечитель торган барлык гыйлми синклит лекцияне тыңлауга катнашты. Щапов, өйдә киенгәнчә, гади кара сюртуктан, гүя үзенең эш кабинетыннан гына чыккан төсле, килеп басты: официаль мундир да, кара фрак белән ак галстук та аның кафедрада күренү өчен нинди дә булса вак хәзерлек алып барганлыгын хәтерләтмиләр иде. Аның йөзе агарган һәм кечкенә кара күзләре бетмәс-төгәнмәс энергия һәм энтузиазм запасы барлыкны сиздертеп ялтырыйлар, гадәттәгедән тизрәк хәрәкәтләнәләр. Бу күзләр өстенә салынып төшкән куе кашлар — аның йөзенә бер ноктага төбәлгәнлек һәм аз гына да төкселек эзе булмаган тирән җиддилек төсе биреп торалар. Шунар Щаповның бөтен фигурасына ниндидер горур, арыслан төсе биргән вак бөдрәле куе чәчләрне китереп куйсагыз, сез аның килеп чыгуының гына да студентлар массасына көчле тәэсир ясавын аңларсыз. Кайбер студентларның алдан шаяртып әйтүләренчә „понеже“ һәм „поелику“ дип сөйли торган юаш һәм скромный кеше урнына, үзенең барлык тышкы простойлыгы белән берлектә мәһабәт бер фигура биек актовая кафедрага җитез атлап килеп күтәрелде. Тынлык урнашты. Щапов үзенең беренче фразасын акрын, ләкин ачык ишетелерлек тавыш белән әйтте: „Алдан әйтим: рус тарихы кафедрасына мин дәүләтчелек турындагы уйлар белән түгел, үзәкләштерү идеясе белән дә түгел, бәлки халык һәм өлкәчелек идеясе белән аяк басам“. — Шуның артыннан ук ул берничә минутка туктарга мәҗбүр булды, чөнки залда ыгы-зыгы купты: барлык масса, ярга тәгәрәп килүче диңгез дулкыны төсле, ничектер берьюлы алга, кафедрага табан елышты һәм Щапов бөтен яклап тыгыз саф булып тезелгән студентлар уртасында калды — һәр яктан аның ялкынлы речь белән электрлашып, сулышларын эчкә йотып, иң нык игтибар белән тыңлаучы фигуралар баскан иделәр“[1].

Университет кафедрасыннан Щапов беренче тапкыр — Россия империясенең һәм патшаларының тарихын түгел, рус халкының тарихын өйрәнергә чакырды. „Тарихта иң төп факт — халык үзе һәм тарихны

---

[1] Казан студентының истәлегеннән. „Первый шаг“ җыентыгы — 1876 ел.

тудыручы халык рухы; тарихның эчтәлеге һәм бөтен барлыгы халык тормышыннан гыйбарәт" — ди Щапов. Россиянең бөтен тарихын ул халык массаларының абсолютизмга каршы өзлексез көрәше итеп карый. Ул өлкәчелек һәм „земское народосоветие", ягни шәһәр һәм авылның ирекле идарә принцибын күтәреп чыкты. Киләчәк Россия аның күз алдына ирекле идарә правосыннан киң файдаланучы аерым өлкәләр федерациясе булып гәүдәләнә. Разин, Пугачевлар җитәкчелеге астында булып үткән халыкның баш күтәрүләрен — Щапов „Халык рухының дәүләткә каршы күренеше, массалардагы демократлык настроениесенең билгесе..." дип карый. Шул ук аңнан, халыкчанлык идеясеннән акрынлап политик азатлыкка омтылу килеп туа. 1812 нче ел сугышыннан соң төзелгән яшерен җәмгыятьләрдә — уянып килүче мораль һәм политик аңның һәм үсешнең төрле омтылышлары чагылдылар. Менә шул җәмгыятьләрнең яшерен җыелышлары аркылы халыкның югары катлау сыйныфлары эчендә конституция идеясе күтәрелде. Шулай итеп, һәр төрле тоткарлыкларга карамастан, политик аңның, халыкның үз-үзен аңлавының һәм үзлегеннән белем алуының акрынлап үсә баруы тиешле җимешне бирә башлады — халыкның политик яктан ирекле идарә идеясен тудырды. Әле пешеп җитәргә, халык рухында үсәргә һәм массалар эченә керергә өлгермәгән бу идея — 14 нче декабрьдә үзенең тарихтагы правосын тантаналы рәвештә иглан итте". Щапов ике сагәткә сузылган беренче лекциясен әнә шул сүзләр белән тәмамлый.

„Бер урында тынып калган тыңлаучылар инстинктив рәвештә олылап аңар юл бирделәр. Залда үлем тынлыгы тагын берничә секундка сузылды һәм кинәт, күк-күкрәгән төсле көчле алкыш тавышлары һаваны яңгыраттылар. Профессорлар да һәм попечитель үзе дә аны котлап кул чаптылар. Шуннан ниндидер күтәренке шатлык тавышлары башланып, профессор артыннан юнәлгән халык кысрыклавы астында сынган мебельләрнең колак тондыргыч шартлавы ишетелде. Барсы да каядыр ашыгалар, үзләренең кайда баруларын да белмичә йөгерәләр һәм ярты сагәт тә үтмәгәндер дип уйлыйм, университеттагы гадәттән тыш вакыйга турында бөтен шәһәргә хәбәр таралып

өлгергән иде инде. Шул көннән башлап Щапов студентлар массасының табынучысына (идолына) әйләнде. Щапов рус тарихы кафедрасын биләп торган кыска бер дәвер эчендә ул университетта хөкем сөрде дип әйтергә мөмкин; аның кафедрада һәрбер күренүе үзенә күрә бер триумфка әверелде. Озак вакыт буенча, Щапов лекция укыган сәгатьләрдә башка барлык профессорлар үз лекцияләрен туктаталар; клиника һәм анатомия театры бушап кала иде".

Щаповның икенче тыңлаучысы, Казан университеты студенты Берннең әйтүе буенча, — „Щапов студентларны аңарчы ишетелмәгән ачыклык, самыймылык һәм кыюлык белән үзенә тарта, ул кешеләр һәм вакыйгаләр турында үзенең барлык белгәннәрен ачыктан-ачык әйтеп бирә. Бер тапкыр ул шулай үзенең лекциясе азагында киләсе лекцияне декабристларга багышлап сөйләячәген әйтте. Лекция билгеләнгән сәгатькә 7 нче аудитория халык белән шыгырым тулган иде. Щапов кафедрага менеп басуга, ишек ачылып попечитель ярдәмчесе Тихомандрицкий керде һәм үз урнына барып утырды. Үлем тынлыгы урнашты... Лектор башта бераз каушаган кыяфәттә, кесәсеннән конспект язылган кагәзне чыгарды һәм кулында бераз әйләндереп торгач кире кесәсенә салды; береаздан тагын шул ук конспектны кулына алып, лекциянең декабристлар хәрәкәте тарихына багышланачагын иглан итте... Ул шундый иркенләп һәм эш иң якын дуслар арасында барган төсле итеп, вакыйганең барлык якларына тукталып сөйли башлады. Щапов үзенең бу лекциясен түбәндәге шигырь белән тәмамлады:

Баш күтәрер бүтән үч алучы,
Туар бүтән көчле токымнар;
Азатлыкка илен чыгаручы
Халык торыр айнып йокыдан.

Кыю телле доцентны көчле давыл шикелле кебек шаулаган алкыш һәм кычкырып әйтелгән мактау сүзләре белән озаттылар".

Ул чагында бу лекция бөтен Россиядә декабристларга багышлап сөйләнгән лекцияләрнең беренче факты диярлек иде.

Тыңлаучы язмасы аркылы безгә килеп ирешкән Щаповның икенче лекциясенә тукталып үтү дә шу-

лай ук әһәмиятле. Бу язмаларның 1863 нче елда, Казан университетының ирекле тыңлаучысы Иван Красноперовны тентегән вакытта алынып, Казан губернаторы канцеляриясенең яшерен бүлегендә гаепләү материалы буларак саклануы да бик характерлы факт. Щаповның „Конституция турында“ дип аталган бу лекциясе шундый сүзләр белән башлана:— „Конституция дигән тылсымлы сүзне ишеткәч кемнең генә йөрәге типмәс? Тизме булыр ул, кайчан без аны күрербез?.. Конституция ул — ирекле хезмәткә хаклы булуны, халыктагы барлык эшләп чыгаручы көчләрнең азатлыгын һәм шушы ирекле һәм эшләп чыгаручы көчләрнең табигый тигезлеген тану дигән сүз... Бары тик экономик көчләрнең һәм хезмәтнең тигез азатлыгы булганда гына, җәмгыятнең тулы, гармоник, төгәл үсеше һәм иҗтимагый, экономик эшләп чыгарышның һәм яхшы яшәү шартларының тигезләнүе мөмкин. Конституция барлык җанлы башлангычларга һәм этнография элементларына ирекле үсеш бирә һәм аларның төрлелегендә, үзара бәйләнешле хәрәкәтләрдә яшәү башлангычын, төрле яклы, җанлы прогрессның залогын бирә“.

Конституция турында ул вакытта дворяннар даирәсендә дә сөйлиләр иде, ләкин аларның конституцияне аңлаулары Щапов анлавыннан никадәрле ерак!. „Россияне төзүче, үстерүче һәм саклаучы“ булган, ләкин карангылыкта изелеп яшәүче крестьяннәр — Щаповның уйларын өзлексез үзләренә тарталар:— „Безнең белем алу тарихыбызда күренешле урын тотучы беренче атаклы кешеләребезне биргән Русь авылының безнең белән тигезлеген, бер туганлыгын танымау яхшы һәм гуманлы булырмы соң? Мәсәлән, тупас иске динчелек һәм юк-барга ышану гасырында рухани сызык буенча беренче реформаларны башлап уздыручы (ул реформалар беренче тапкыр нинди генә төстә булсалар да) кем булды? Нижегород крестьяненең улы Никон булды. Земское народосоветие турында һәм ул вакытта төньяк Европада әйтелмәгән һәм 19 нчы йөздә дә әле үзләренең тормышка үткәрелүен көткән югары политик идеяләрне кыю рәвештә император Петр Великийгә башлап беренче тапкыр такдим итүче кем булды? Үзенең атаклы әсәрләрендә шул фикерләрне әйтүче кеше Новгород

крестьянине Посошков булды. Безнең яңа әдәбиятыбызга, поэзиябезгә һәм фәнебезгә башлап нигез салучы кем иде? Холомогор крестьяненең—балыкчысының улы Ломоносов иде, һ. б. Әгәр дә һәрбер чиркәү һәм застава янындагы патша кабагына илтә торган бердәнбер такыр юл ябылып, аның урнына һәрбер өлкә шәһәрендә университетларга юл ачылса, үсү өчен җинел шартлар тудырылса, шуңар ирек бирелсә — фән өлкәсендә, әдәбиятта, цивилизациянең бөтен тармакларында үзлегеннән туган талантлар никадәрле күбәерләр иде".

Бу карашлар Щаповны үз заманының иң яхшы алдынгы кешеләре рәтенә куйдылар һәм безнең көннәрдә, — ул өметләрнең һәм теләкләрнең тормышка ашырылган көннәрендә, — моннан 80 еллар элек университет кафедрасыннан әйтелгән ул речьләр Щаповның кыюлыгына соклану, таңга калу тойгысы тудыралар.

Щапов Казан университетында бары бер генә ел, 1860—1861 нче уку елында булды. Студентлар арасында уңыш казануга карамастан, Щапов үз теорияләрен нигезләү өчен белеме җитмәгәнлеген сизә һәм белемен тирәнәйтү өчен Москва белән Петербургга командировка бирүләрен сорап шушындый прошение яза: „Башкалаларга баруны бик кирәкле дип саныйм. Университет белеме алмаганлыгымнан һәм рус университетларында тарих тыңламаганлыгымнан, рус тарихын укытучы башка профессорлар белән, мәсәлән, Соловьев, Костомарев белән һәм аларның дәрес укытудагы практик методлары белән танышуны файдалы саныйм". Щаповны шулай ук Москва һәм Петербург көтепханәләре һәм архивлары да кызыксындыралар. Бу прошение 1861 нче елның 12 нче апрелендә тапшырылган. Шул ук көнне Щаповның бөтен эшчәнлегенә йогынты ясаган һәм аның алдагы бөтен тормышын үзгәрткән вакыйга була.

Крестьянлек реформасы турындагы 1861 нче ел 19 нчы февраль „положениесе" 5 нче мартта иглан ителде. „Беренче помещик Александр II, бунтлардан куркып, түбәннән күтәреп ташлауларын көткәнче, югарыдан азатлык бирү яхшырак дип тапты" (Ленин). „Азатлыкка чыгару" крестьяннәр көткәнчә булып чыкмады. Бу „азатлык" крестьяннәрне үтә вәҗдансыз

рәвештә талау, аларны тоташ мәсхәрәләү, көчләү булып чыкты". Караңгылыкка баткан, изелгән крестьяннәр аптыраганлыктан, бу „ирек"не чиновникларны сатып алган помещиклар алмаштырган ялган ирек дип карадылар. Өстәвенә „положение" үзе „зур форматта брошюраланган калын бер китаптан гыйбарәт иде; помещик крестьяннәреннән берсе дә аны аңлый алмаган булса кирәк, чөнки алар арасында укый-яза белүчеләр бөтенләй юк иде, шуңа күрә зур калын кирпич формалы бу китапны укырга бер кеше дә табылмады һәм ул аны китергән чиновник кайда калдырган булса, шунда һичбер хәрәкәтсез ята бирде[1].

Шулай булуга карамастан, крестьяннәр арасында „положение"дән „чын" ирек турындагы сүзләрне эзләүчеләр, „укучылар", „аңлатып бирүчеләр" һәм крестьяннәрне помещиклар өчен һичбер нинди эш эшләмәскә өндәүчеләр табылды. Крестьяннәр боярга эшләүдән һәм оброк түләүдән баш тарта башладылар, ә кайбер урыннарда помещикларның җирләрен, урманнарын тартып алырга да керештеләр. Бөтен Россия буйлап крестьян кузгалышлары җәелде. Бу крестьян хәрәкәтенең иң трагедияле эпизодларыннан берсе тарихта билгеле урын тоткан „Бездна вакыйгаләре" булдылар.

Казан губернасының Спас өязендәге Бездна авылында, Сенатор Мусин-Пушкин имениясендә Антон Петров исемле „аңлатып бирүче" крестьян бар иде. Халык аны тыңлау өчен Безднага агылды. Бу хәрәкәт Казан губернасының Лаиш, Чистай өязләрен, һәм Самара, Сембер губерналарының бер өлешен үз эченә алды. Безднага дүрт меңнән артык халык җыйналды, чөнки Петров әйтүенчә Безднага „чын ирек"не иглан итү өчен „патша вәкиле" килә имеш дигән хәбәр таралган була. Исправник, Петровны кулга алырга теләсә дә, халык бирми. Шуннан соң Безднага — крестьян кузгалышларын басу турында махсус йөкләмә алып күптән түгел генә Казанга җибәрелгән граф Апраксин кул астында берничә рота пехотадан торган гаскәр килеп төшә.

Аңгыра һәм куркак характерлы Апраксин крестьян-

---

[1] Казан губернаторының адъютанты Половцев истәлекләреннән. „Исторический вестник", 1907 ел, ноябрь.

нәрне янап һәм сүгеп сөйләгән речьләре белән бер нәрсәгә дә ирешә алмый, священникның үгет-насыйхәтләре дә нәтиҗә бирми. Халык аларга бер сүз әйтмичә үзен тыныч тотса да, Петровны бирмәс өчен таралырга теләми. Апраксин халыкка атарга приказ бирә. Ләкин халык баскан урыннан китми һәм бары тик бишенче залптан соң гына тарала башлый. „Бөтен урам үтерелгән һәм яраланган кешеләр белән тулды. 71 кеше үтерелгән, 15 кеше яраланган булып чыкты. Чынында аларның саны күбрәк булган, чөнки күп кенә үтерелгән һәм яраланган кешеләрне крестьяннәр халык арасыннан чыгарып, авылларга алып киттеләр; икенче көнне Казаннан килгән һәм ике ай буена яралыларга ярдәм күрсәткән докторның исәбе буенча барлык корбаннарның саны 350 кешедән артык иде“[1].

Бу канлы вакыйга турындагы хәбәр Казанга барып җиткәч тә, университет һәм духовная академия студентлары „туган илгә мөхәббәт һәм азатлык өчен үтерелүчеләр“не искә алып демонстратив панихида оештыралар. Панихида зиярәт чиркәвендә студентлар хорының катнашы белән үткәрелә. Азактан профессор А. П. Щапов күзләре яшьле хәлдә, дулкынлы речь сөйли. Ул речьнең түбәндәге тулы тексты Октябрь революциясеннән соң гына билгеле булды:

— „Һәм сез, дуслар, — дип сөйли башлый А. П. Щапов, — бөтен халык күптән көткән азатлык өчен көрәштә деспотизмның беренче корбаннары булдыгыз. Сез беренче башлап безне йокыдан уяттыгыз, һәм халык политик хәрәкәттә инициатива күрсәтергә сәләтсез имеш дигән хаксызга шикләнүебезне үзегезнең инициативагыз белән юкка чыгардыгыз. Сез эшләп килгән һәм җимешләре белән безне тукландырган җир, үзегез ана хуҗа булырга теләгән һәм үтерелгәннән соң сезне җәзаланучылар итеп үзенең эченә алган җир — халыкны баш күтәрергә, азатлыкка чыгарыр. Туфрагыгыз тыныч булсын һәм үз-үзегезне кызганмыйча күрсәткән батырлыгыгыз тарихта мәңге яд ителсен. Яшәсен демократик конституция!“.

Икенче көнне үк духовная академия ректоры Щаповка отставкага чыгарга куша.

Губернатор исә, панихида турындагы хәбәрне

---

[1] Половцев истәлекләреннән.

ишетү белән эчке эшләр министеренә „бик яшерен" телеграмма җибәрә: „Кичәгенәк зиярәттә студентлар һәм академиклар Безднада үтерелүчеләргә багышлап панихида уздырганнар. Полиция бу хәлне панихида тәмам булгач кына ишеткән; барсы да тыныч үткән, ләкин профессор Щапов панихидадан соң нәрсәдер сөйләгән... Ишетелүенә караганда кайбер студентлар, вакыйгаләрнең ничек булуы белән танышу өчен Спасскигә киткәннәр..." Бу телеграмма — Петербургдагы түрәләрне аптырашта калдыра. Александр II аеруча Щаповның панихидадан соң нәрсә турында сөйләгәнлеген белергә тели. Ләкин речьнең тексты полиция өчен билгесез кала, чөнки кагәзгә язылган бу речьне Щапов кулыннан ниндидер студент алып өлгергән була. Щапов нәрсә турында сөйләде дигән сорауга, Казан губернаторы түбәндәге тегерамма белән җавап кайтара: „Щапов — баккалавр. Архиепископ аңар речьне китереп бирергә кушкан. Щапов тапшырмаган. Жандармнар да белә алмадылар. Миңа ул речьнең аерым өзекләре генә билгеле. Анда ул Христосның өйрәтүе демократик иде, ул хәзерге безнең туганнарыбыз төсле азатлык өчен үлде, хезмәт ияләре үзләренең мангай тирләре белән сугарылган кырларын үз каннары белән ашладылар, тиздән Россиянең азатлыкка чыгу минуты җитәр дигән һәм конституция турында нәрсәдер әйткән. Щапов үзе күтәренке күңелле, тәкәббер, эчкече, ләкин акыллы. Архиерей тарафыннан отставкага чыгарылган һәм священник правосы белән панихида укыган ике монах, минем уемча, зарарлы кешеләр". Патша бу телеграмманың өстенә болай дип яза: „Щаповны кулга алырга, ә ике монахны Соловецкий монастырьгә ябарга кирәк". Бу эшләрне тикшерү өчен Петербургдан генерал-адъютант Бибиков җибәрелә.

Хәлнең катлауланып китүеннән куркып, Щаповны Казанда кулга алмыйлар, бары тик аның өстеннән яшерен күзәтү генә куялар. Казан учебный округының попечителе князь Вяземский дә Щапов кулга алына калса студентлар арасында чуалыш чыгар дип курка. Вяземскийнең Бибиков белән һич шиксез сүз беркетеп әйткән киңәше буенча, Щапов Петербургга үзе барып аңлашырга карар бирә.

1861 нче елның 26 нчы апрелендә Щапов юлга

чыга. „Язгы аяз иртә иде, академия һәм университет студентлары аны озатырга җыелдылар; алар аның квартирына, коридорына, өй алдына һәм академия флигеленең крыльцосына тулдылар. Саубуллашу тулкынландырырлык иде һәм Щапов ачы күз яшьләре белән елады. Студентларның бер өлеше көймәләргә утырып, Подлужная бистәсеннән башлап, ташып җәелгән Казанка елгасы буйлап, пароход пристаньнәренә кадәр озата бардылар... Озатучылар да, Щапов үзе дә, „Самолет“ пароходында аның өстеннән юл буенча күзәтеп, һәрбер хәрәкәтен, сөйләгән сүзен тикшереп бару эше йөкләтелгән жандарм офицеры Корягинның көтеп торуын белмәделәр, ул хәл аларның башларына да килмәде[1]“.

Щаповны Нижнидә кулга алдылар. Беренче май көнендә Щаповның Нижнидән Москва аша Петербургга озатылуы турында телеграмма алынды. А. П. Щапов тормышының Казан чоры әнә шулай бетә. Казан турында аның башында иң күңелсез истәлек кала һәм бик озак еллар кулдан-кулга аның шундый бер шигыре йөри:

## КАЗАН

Гайбәт белән тузан шәһәре,
Төрле бизгәк белән чирле син.
Елан кебек миңа зәһәрле —
Судым булган көннән бирле син.

Кочагында сигез ел тоташ
Будың мине. Барсын күтәрдем.
Нәләт укып, азап аралаш
Көннәремне синдә үткәрдем.

Мужикларның авыр язмышын
Күреп акты күпме күз яшем.
Тыңламадың ярлы дьяк улын,
Аңламадың аның киң уен.

Әй кызганыч шәһәр! Миннән син
Мәзәк көттең; дәрес урнында,
Көлке өчен, гүя, чыгыш ясыйм
Дип уйладың минем турымда.

Мәзәк өчен хезмәт итү түгел —
Минем бурыч. Шуны бел, шәһәр;

---

[1] Аристов — „А. П. Щапов“.

Укытучы — изге җсем ул,
Тап төшертмәм һичбер мин аңар.

Барын әйттем сиңа хәл кадәр
Туры итеп, ачык аңлатып.
Аягымнан хәзер сиңа, шәһәр,
Тузаннарны төшерәм мин кагып.

Йокла, шәһәр, тәмләп йоклачы!—
Баш күтәреп мужик чыкканчы.
Тыңламадың ярлы дьякон улын,
Аңламадың аның киң уен[1].

2.

Петербургда Щаповны турыдан-туры III отделениегә китерделәр[2]. Сорау алган чагында панихидага кемнәрнең катнашулары белән кызыксындылар. Щапов, фамилияләрне белмим, дип җавап бирде. Бер үк вакытта Казанда да тикшерү барды. Панихида укучы монахлар кулга алындылар, студентларга допрос башланды.

Щапов III нче отделениедә утырган көннәрдә патша исменә хат яза һәм үтерелгән крестьяннәрне искә алу панихидасына үзенең катнашканлыгын, бу чыгышка аны нинди тойгылар этәргәнлеген ачыктан-ачык күрсәтеп уза. Ул Бездна вакыйгасенең үзендә чиновникларның башбаштаклыгына каршы ачу һәм рәнҗү тойгысы уятканлыгын һәм ул чиновникларның халыктагы омтылышларны, халык караңгылыгының тирән ачысын аңламауларын әйтеп яза. Щапов халыкны агарту турында көенеп, крестьяннәргә мәктәпләр ачу өчен галимнәр өстенә салым кертергә тәкдим итә: „Без, галимнәр, халык түли торган үз жалованиебездән авыл һәм халык мәктәпләре өчен салым түләргә тиешбез“. Шушы хатында Щапов халыкны укыту эшен үзгәртеп кору турында үз проектын эшләп бирә һәм иң төп мәсьәлә итеп уку эшендә сословиесезлек кертүне ала: „укып белем алырга һәркемнең хакы бар“ — ди ул. Шуннан соң ул патшага дәүләтне үзгәртеп кору планы тәкдим

[1] Николай Агафоновның „Из Казанской истории“ исемле китабыннан, 1907 — Казан.

[2] Патшаның үз канцеляриясе каршындагы III отделение жандармнар корпусына һәм полициягә җитәкчелек итә иде.

итә һәм аның уенча, бу план — халыкка бәхет китерергә тиеш була. Үзгәртеп кору эше — волость һәм шәһәрдән башлап үзәккә хәтле Земский советлар оештырудан гыйбарәт. Һәрбер өлкәдә шул өлкәнең эшләре белән идарә итүче өлкә советлары булырга тиеш. Советларга сайлаулар „Сословиесез, ягни барлык кеше катнашып тавыш бирү" юлы белән үткәрелергә тиеш. Үзәк Земский Совет өлкә һәм гомуми дәүләт эшләре, финанс, гаскәр, тимер юллар белән идарә итә. Щаповның проектында самодержавачы патша бөтенләй искә алынмый. Щапов дәүләт идарәсенең шушындый формаларын крестьяннәр өчен иң якын һәм алар гомерлеккә „кушылачак" формалар дип хисаплый. Аныңча мондый дәүләт төзелешендә интеллигенция үз өстенә „әхлакый диктатура" эшен алырга тиеш. Щапов бу социаль реформаны тыныч юл белән тормышка ашырырга уйлый. Аңар демократик конституция үзе генә дә барлык эчке каршылыкларны хәл итә ала һәм азатлык, туганлык, тигезлек принципларына нигезләнгән тормышны кора ала кебек тоела. Ниһаят, Щапов цензураны бетереп, матбугат өчен тулы азатлык, фикерләрне ачыктан-ачык әйтергә рөхсәт бирелүен, „һәрбер әсәрнең авторы җаваплылыгына тапшырылуын" таләп итә.

Патшага тулы ышаныч белән язылган бу хат, Щаповның дөньяга карашында беркадәр балаларча җиңеллек булуын һәм аның иҗтимагый-политик идеяләренең характерын ачык күрсәтә.

Бу вакытта инде Щаповның исеме Петербург җәмгыятенең прогрессив катлавына киң рәвештә таныш була. Бу катлау Щапов эшенең нәтиҗәсен бик зур борчылу белән күзәтә. Шушы катлауның басымы астында хөкүмәт 1861 нче елның августында Щаповны азат итәргә мәҗбүр була. Ләкин аны зарарсызландыру һәм күзәтү астында тоту өчен, эчке эшләр министерлегенең управляющие Валуев аңар министерлектә раскольниклар эше буенча хезмәт урны такдим итә һәм хезмәт йөкләмәләре белән исәпләшмәстән гыйлми эш белән шөгыльләнергә мөмкин булуын әйтә.

Фәнни-тарихи эшләр башлау турында хыялланган

һәм министерлек архивыннан файдаланырга өметләнгән Щапов бу такдимгә риза була.

Щаповның азатлыкка чыгуы аңар карата аннан башка да зур булган интересны көчәйтте, аның исме Бездна вакыйгаләреннән соң бик популярләшкән иде, шунлыктан аның квартирына китап басучылар, әдипләр, аңа теләктәшлек итүчеләр һәм болай кызыксынучылар килеп йөри башладылар. Алдынгы журналлар үз битләрендә аңар үзләре теләп урын бирәләр. „Отечественные записки" журналының янындагы номерларында аның „Великоруссляр яшәгән өлкәләр һәм чуалчык заман — (Смутное время)—" исемле мәкаләсе басылып чыга.

Ләкин көтмәгәндә Щапов турында патша яңа бер карар чыгара. Ул карар — духовная академиядә укытучы булуына бәйләп Щаповның эшен Святейший синодда карау уңае белән килеп чыга. Синодның карарын раслаган чагында государь император бакалавр Щаповны, аның җәзасы исәбенә арест астында булуын, Казан университетындагы укытучылык хезмәтеннән алынуын һәм Казан духовная академия начальникларының анардан 450 сум акча түләтүләрен кертеп, шулардан тыш аны акылга һәм әдәпкә өйрәтү өчен Святейший синод кушуы буенча монастырьгә җибәрергә боерды".

Патшаның бу карары билгеле булгач та ризасызлык һәм нәфрәтләнү тавышлары күтәрелә. Башларында Н. Г. Чернышевский торган язучылар протест кагәзе төзеп, Щаповны яклап кул куйдыра башлыйлар. Бу протестта болай әйтелә: „Беткән дип исәпләнгән эш буенча яңа карар чыкты, бер распоряжение икенчесе белән бетерелде. Моннан соң хөкүмәтнең үз-үзенә турылыгы турында нинди фикер булуы мөмкин? Бер җәза икенчесе белән тирәнәйтелә — шулай булгач, уголовное праводагы бер җинаятче ике җәзага хөкем ителми дигән төп принципның хөкүмәт тарафыннан үтәлүе турында хәзер нинди фикер булуы мөмкин? Икенче җәзаның төре — монастырьгә сөргенгә җибәрү — хөкүмәтнең 19 нчы йөзнең соңгы яртысы белән урта гасырлар арасындагы аерманы сизүен күрсәтәме?". Шуннан соң протестта Щаповның ауру икәнлеге, даими медицина ярдәменә мохтаҗлыгы, шунардан башка Щаповның һәләк була-

чагы, „шул чагында җәмгыять Щаповның үлеме өчен хөкүмәтне гаепле санарга хаклы булачагы“ әйтелә.

Щаповның эше бик озак билгесез хәлдә ята, бары тик 1862 нче елның 19 нчы февралендә генә патша Щаповны монастырьгә җибәрмәскә, „гафу итәргә рөхсәт бирә“.

Алдан көтелгәнчә үк, Щаповның эчке эшләр министерлегендәге хезмәте озакка сузылмады, ул анда бер ел чамасы гына эшләде. Министерлектәге чиновниклар белән якынрак танышкач, ул аларның тар карашлы булуларына түзә алмыйча, кискен төстә сүз көрәштерә башлады. Аның саф күңеллелеген чиновниклар мыскыллы елмаю белән каршы алдылар. Ә инде ул үз өстендә цензура изүен сизгәч (аның мәкаләләрен басудан тыйдылар), тирәннән кәефе бозылды һәм ул министерлеккә йөрүдән туктады. „Рус дворянлыгы турында“ дигән, ләкин матбугатта чыкмаган, мәкаләсе өчен ул рәсми рәвештә министерлектәге хезмәтеннән чыгарылды. Шуның белән берлектә патша чиновниклары да Щаповны юашландырып, кулга иярләштереп булмаячагына ышандылар.

Хезмәттән бушатылгач, Афанасий Прокофьевич Щапов журнал яки газета чыгару эше белән шөгыльләнергә карар бирә. Ләкин үзен „ышанычлы кеше“ итеп танытмаган Щаповка патша хөкүмәте журнал чыгарырга рөхсәт бирми. Берникадәр вакытлар Щапов „Век“ журналына язышa. Бу журнал агалы-энеле Курочкиннар, И. Ф. Горбунов, Н. С. Лесков, Н. В. Успенский, П. И. Якушиннар катнашы белән чыгарылып килә. 1862 нче елны аның битләрендә Щаповның берничә мәкаләсе басыла һәм ул аларда инде тәмам формаланып җиткән өлкәчелек теориясн төрле яклап яктырта. Бер үк вакытта Щаповның мәкаләләре „Отечественные записки“ журналында да басылып баралар.

Н. Г. Чернышевский һәм аның журналы „Современник“ — Щаповның дөньяга карашына бик зур йогынты ясый. Чернышевский бер вакыт Щапов белән очраша һәм озак кына беседа алып бара. Бу беседаның эчтәлеге билгесез булып калса да, шуннан соң Щаповның борынгы Русь җәмгыятендәге тормыш формаларын идеаллаштырудан баш тарткан-

лыгы һәм аларга критика аша карый башлавы билгеле. Шул ук вакытта ул славяно-фильлек идеяләреннән арына һәм иң әһәмиятлесе — „дөньядагы ачлык һәм ярлылыкны һичбер нинди тарихи-юридик, яки административ чаралар белән генә бетерергә мөмкин түгел“леген аңлый. Ул үзенең элек берничә тапкыр күтәреп чыккан һәм — „рус халкының тормыш шартларын яхшырту мәсьәләсе дәүләтнең яхшы учреждениеләренә, акрынлап үткәрелүче политик реформаларга бәйләнә“ дигән фикеренең ялгыш булуын икрар итә. Щапов үзе бу яңа фикерләргә Н. Г. Чернышевскийнең китерүен күрсәтеп уза.

Патша хөкүмәте Щаповны һич кенә дә тынычлыкта калдырмый. Аның „Земство һәм раскол“ исемле китабы басылып чыкканнан соң, изге урыннарга сәяхәт итеп йөргән реакцион язучы А. Н. Муравьев — зур түрәләрнең берсенә Щаповның зарарлы теория таратуын әләкләп хат яза. Муравьев шундый „иркенлек“кә юл калдырмас өчен цензураны көчәйтүне таләп итә. Аның хатында Щаповка карата түбәндәге сүзләр әйтелә: „Ул китапның эчтәлегендә раскол — земствоның хөкүмәткә каршы протесты дигән фикер үткәрелә һәм расколның характеры да дини итеп түгел, бәлки гражданлык төсендә итеп күрсәтелә. Авторның әйтүе буенча раскол — халыкның ризасызлыгын чагылдыра. Барлык кайгы—бәхетсезлекне, халык бунтларының барлык элементларын ул халыкның йөз еллар буена яшәп килгән бердәмлегенә, заговорына, доктринага туплап күрсәтә. Стенька Разин хәрәкәтенең рухы, стрелецлар рухы үлми торган җанлы раскол оппозициясе булып гәүдәләнә. Бу бит — һәр нәрсәдә тигезлек урнаштыруны таләп итүче һәм боярлар белән чиновникларга каршы өзлексез чыгышлар белән баручы чын коммунизм... Раскол фәкат нindидер яңа пугачевчылык хәрәкәте күтәрү өчен бер корал, рычаг итеп кенә алынган“.

Чынлап та, Щапов расколны дини күренеш кенә итеп түгел, бәлки тарихи һәм социаль бер күренеш итеп караучы беренче галим булды. Ул расколның килеп чыгу сәбәпләрен халыкның экономик һәм политик тормышыннан эзләп табып күрсәтергә тырышты. Беренче планга экономик-иҗтимагый элементларын куйган бу теория Муравьевны куркытты, чөнки

ул яшәп килүче стройны читләтеп тәнкыйтьли һәм шунардан нәтиҗәләр чыгарырга фикерне уята иде. Муравьевның доносы белән бер үк вакытта Щапов „Лондон пропагандачылары“ — ягни Герцен, Огарев, Бакунин белән багланыш тотуда гаепләнүче кешеләр эше буенча җавапка тартыла, бары тик шул турыда хәбәр итүченең күрсәтүләре бик буталчык булганга күрә генә, Щаповны гаепли алмыйлар.

1861 нче елны Щапов Герценнән хат ала. Герцен аны гыйлми хезмәтләре белән котлап, байракны төшермәскә, бәлки шул ук юл белән баруда дәвам итәргә киңәш бирә. Хат түбәндәгечә тәмамлана: „Хәзерге рус язучыларының ватылган һәм карлыккан тавышлары арасында сезнең саф һәм көчле тавышыгыз бердәнбер диярлек күңелле тавыш булып яңгырый һәм йөрәккә тирән үтеп керә“. Щапов Герценнең үзенә игтибар итүенә куанып, аңар цензура тарафыннан тыелган „Рус дворянлыгы турында“ исемле мәкаләсен җибәрә.

Крестьян реформасыннан соң бер ел вакыт үткәч, хөкүмәт тирәсендә реакциягә күчү сизелә. Әдәбиятка һәм аның вәкилләренә каршы эзәрлекләү башлана: Чернышевский белән Писарев Петропавловск крепостенә утыртылалар, алар редакциясендә чыгучы „Современник“ һәм „Русское слово“ журналлары ябыла. Халык арасында уку-агарту эшләренә һәм фәнгә каршы эзәрлекләү көчәеп, университетлар, якшәмбе мәктәпләре ябылалар (жандармнар ул уку йортларында „җимерүче таглиматлар, ышанмаучылык, материализм һәм социализм өйрәтелә“ дип донослар язалар.)

Хәтта, язучылар җыйнала торган һәм ара-тирә Щапов та кергәләп йөри торган шахмат клубына хәтле ябыла.

Щаповка бу әйләндереп алган обстановка бик авыр тәэсир итә һәм ул шушы вакытта гражданлык сагышының сәбәпләре турында поэтик фикер йөрткән оригиналь бер әсәр — „Гражданлык сагышы“н яза: Табигыйлек, кешечәнлек һәм гражданлылык — менә уй юнәлә торган өч иң зур, төп идеяләр шулар. Бу — кешеләр арасындагы социаль багланышлардагы ялганны, табигыйсезлекне тирәннән сизеп җитлеккән аң... Радищев шушы сагыш белән сугарылган иде...

Гражданлык сагышы нечкә йөрәкле Радищевне һәләк тә итте... Үлмәс Рылеевнең тирәннән — йөрәктән әйтелгән уйлары да шушы изге гражданлык сагышыннан башка нәрсә түгел иде... Политик уй һәм гражданлык тойгысы тарихында — 14 нче декабрьдән башлап 1856 нчы елга кадәр үткән авыр, сагышлы еллар — гражданлык сагышының аеруча газаплавы белән билгеләнделәр. Бу деспотлык заманында ул, мәсәлән, Лермонтов поэзиясендәге төсле, күңел кайтуга һәм өметсезлеккә барып җитте. Бу чагындагы гражданлык сагышы „Акылдан кайгы“да да, „Күз яше аша көлүдә“ дә чагылды. Гражданлык бәхетсезлегенең бөтен авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән үлмәс халык шагыйре Кольцов, йөрәк өзгеч кайгы тавышы белән үзенең гражданлык сагышын — авыр кайгысын бушатып ерлады. Ә бәхетсез Шевченко? Ә Герцен? Безнең җәмгыят тормышыбызда нәрсәгә генә карасаң да гражданлык сагышын кабыза“. Һәм Щапов ярлылык белән байлыкның күзгә бәрелеп торган мисалларын китерә: ямаулы киемнәр кигән мужиклар артелен ул алтынга манчылган генераллар һәм бизәнгән барыняләр — княгиняләр белән янәшә куеп, чагыштырып күрсәтә. „Шулар шикелле үк кешеләр бит ул мужиклар. Алар да бит чабатадан матуррак әйберләрне, кара ипидән тәмлерәк ашларны телиләр. Невский проспектка чыксаң төрле нәселле, төрле сословиеле, төрле өлкәләрдә яшәүче, чуар Россия империясен уч төбендә кебек күрәсең. Һәм уй ирексез рәвештә бөтен рус халкына һәм Россиядәге барлык рус булмаган халыкларга, халыкның провинциядә яшәүче өлешенә һәм күбесенчә бик гади халыкка күчә. Нева елгасының дулкыннарына карыйсың да, сагышлы уйларга батасың, — цивилизация һәм житешле тормыш җимешләренең халык арасында шушылай тигез правосыз, тигез үлчәүсез бүленешенә кайчан чик куелыр? Һәм хөкүмәтне һәм халыкны алдаучы официаль статистика таблицаларына караган вакытта да әле, шушындый тигезсезлек контрастларына таң каласың“.

Щапов җир бүленеше турындагы саннарга да анализ ясый: „Иген игелерлек 365 миллион десятинә җирдән крестьяннәргә барлыгы 3,7 миллион десятинә генә, ягни 1% кына тигән. Калган җирләр шул ук

крестьяннәрдән салым һәм оброк алучы помещиклар һәм казна кулында... Көнчыгыштагы инородецлар һичбер культурасыз борынгы кыргыйлык хәлендә катып калганнар, безгә инде аларны тулай европа семьясенә алып кертергә, аларга үзебезнең көнчыгыш туганнарыбыз итеп, белем һәм ирекле праволар бирергә тиешлегебезне аңларга вакыт".

Щаповның бу тәмам булып җитмәгән, ләкин үзенең самыймыйлыгы белән бик көчле бер әсәр итеп язылган уйлары, ул вакыттагы Россиянең җәмгыят һәм дәүләт тормышының критик картинасын бирә һәм Щаповның алга баруында тагын бер зур адым ясаганлыгын күрсәтә: аның алдында сыйнфи чикләнешләр бөтен буйлары белән килеп басалар.

Щаповның дәүләт һәм социаль мөнәсәбәтләрне тыныч юл белән үзгәртү турындагы өметләре шулай итеп тулысынча җимереләләр. Ул үзенең дөньяга карашын тагын бер тапкыр тикшереп уза. „Тормышының соңгы елларында шиккә төшүләрнең газаплы, борчулы көрәшен кичергән һәм үз акылының элекке төзелешен җимергән кешеләр сирәк табылыр. 20—25 яшьлек вакытта урнашкан дөньяга карашында һәм фикер йөртү образында, үзенең барлык белемнәрендә 30—35 яшькә җитү белән генә шиккә төшүчеләр аз була. Шулай ук, бөтен гомре буенча шиккә төшеп үзенең ялгышуларын, адашуларын аңлап, төзәтеп, критик уй белән һәм акылның тулы философик азатлыгы белән чынлыкны эзләп армыйталмый эшләүчеләр сирәк табылыр", — дип яза Щапов һәм югарыдагы сүзләрдә ул үзен, үзенең тынгысыз натурасын гәүдәләндерә.

Ул нигезенә — тарихи процессларны материалистларча аңлату яткан яңа бер әсәр — „рус халкының фикер үсешендә социаль-педагогик шартлар" исемле китабын яза.

Ул кеше табигатнең өлеше һәм материаль среда белән өзелмәслек бәйләнгән, бары тик материаль ихтияҗ гына җәмгыят тарихы дип аталучы нәрсәне тудыра — дигән фикергә килә.

Эзәрлекләү астында — ярым легаль хәлдә яшәүче Щаповны Сибирьгә, III отделение чиновнигының әйтүенчә „туган җиренә" сөрәләр. Щаповның ауру булуы аркасында аны сөргенгә җибәрү карарын үз-

гәртүне сорап мөрәҗәгать итүләргә каршы — сөргенгә китүен язга хәтле кичектереп тору җавабы гына бирелә һәм анда да ул хәрби госпитальнең арестантлар бүлегендә бик нык күзәтү астында ятарга мәҗбүр ителә.

Афанасий Прокофьевичнең бу вакыттагы тормышында бер якты вакыйга була, ул Ольга Ивановна Жемчужниковага өйләнә һәм аның иптәше бу вакытта аңар кияүгә чыгуы белән сөргенгә җибәрелүче галим тормышындагы барлык кыенлыкларны уртаклашырга хәзер икәнлеген күрсәтә һәм үз-үзен аның белән сөргенгә бергә алып китәргә тәкдим итә.

Щаповлар Сибирьгә 1864 нче елның көзендә киләләр. Афанасий Прокофьевичне башта Анга авылына, туган авылына сөрәләр, ләкин соңыннан Иркутскига күчәргә рөхсәт бирәләр. Аларны анда юлдагы шәһәрләрдәге танышлардан һичбер кем белән дә күрешергә рөхсәт итмәүче, кемне дә булса алар янына керткән вакытта да кеше башына 25 сум акча алучы жандарм озата бара.

Сибирьдә Щаповлар бикләнеп яшиләр, әйләнәдәге җәмгыятьнең интереслары алар өчен чит була. „Һәр урында фикернең кайгылы һәм куркыныч апатиясе һәм табигаттәге тупас көчләрнең тантанасы кеше акылы өстеннән хөкем сөрә" (Щапов).

Озакламый Щапов өчен тагын бер күңелсезлек килеп чыга; „Сибирьдәге управление тәртипләрен җимерергә һәм аны империядән аерырга омтылучы кайбер яшь кешеләрнең явыз ниятле хәрәкәтләре" турындагы эшкә аның исмен дә бәйлиләр. Щаповны Омск каласына озаталар, ләкин гаепләрлек нәрсә таба алмыйлар. Бу эш буенча җавапка тартылучыларның бер гаебе итеп, аларның „Томские губернские ведомости" газетасына Сибирьгә университет оештыру турында мәкалә язулары күрсәтелә. Аларга чиновниклар „Сездән бу турыда кем сорады?" диләр. Щапов мондый теләкләрне берничә кат күтәргән кеше буларак әлбәттә „гаепле" иде. Чөнки ул Александр II гә язган хатында да Иркутск каласында университет ачарга кирәклеген язган иде.

1866 нчы елны Щапов үзенең иптәше Ольга Ивановна белән бергәләп Турухан краен өйрәнүче

экспедициягә катнаша. Щаповның Туруханда яшәүче кешеләр турында фән өчен бай материал бирүче бу хезмәтләре, кызганычка каршы, Иркутскидагы 1879 ел пожарында янып юкка чыгалар. Соңрак елларда Щапов югары Лена краен өйрәнү экспедициясенә дә катнаша.

Хөкүмәт Щаповларны Россиянең культура үзәкләреннән бик нык рәвештә ерак тота. Баштарак әле Ольга Ивановнаның туганнары ярдәме белән аларның материаль хәлләре рәтле була. Соңгы елларда инде алар чын-чыннан авыр нужа кичереп яшиләр. Петербург журналларында басылган мәкаләләр өчен түләнә торган гонорар акчалары бик очраклы килер булып кына хезмәт итәләр. Ольга Ивановна эш эзләсә дә озак вакыт таба алмый, соңыннан гына ул кызлар гимназиясенә укытучы булып урнаша ала.

Ольга Ивановна педагоглык эше белән бик нык кызыксына, аңар ул бик җидди эш итеп карый һәм үзенең педагоглык методларын уйлап чыгара.

1872 нче елны Ольга Ивановна тиф белән аурый һәм терелгәч тә эшкә тотына алмый. Щапов үзе дә авырып түшәккә ята. Чын-чыннан ярлылык башлана. 1874 нче елның февралендә Ольга Ивановна үлә. Аның турында Щапов түбәндәгеләрне язып калдыра:

— „Ул табигат тарафыннан югары акыл таланты белән бүләкләнгән, һәм гадәттә очраучы акыл сәләтеннән кискен рәвештә аерылып, күзгә бәрелеп торган хатын иде. Ун ел буенча мин аны һәр көн, һәр сагәт өйрәнеп килдем һәм киләчәктәге барлык яхшы, чын антропологик — кешелекле — генерацияләргә йөрәгемнең иң тирән җиреннән ялварып, васият итеп әйтәм: хәзер әле билгесез, ләкин хәзерге җәмгыяттә сирәк очраучы хатын булган О. И. Щапованың (Жемчужникованың) кече күңелле, ләкин күпне аңлатучы исмен киләчәктәге чын кешелек — социаль-кооператив ассоцияләрнең байрагында искә алыгыз. Сибирьдә әле мондый хатын булганы юк иде һәм тиз генә булмас та ахры. Мин аның бөек тыйнаклылыгы аркасында бу юлларны һәм шушы үзенең кыскача биографиясен юк итәргә кушачагын беләм. Ләкин минем барлык язганнарымны юкка чыгарыгыз, бөтен тормышымны тартып алы-

гыз, рус әдәбиятында язган һәм бастырган барлык хезмәтләремне утка яки суга ташлагыз, бары тик мин сездән, киләчәктәге шушы хәзерге Сибирь һәм Россиядә яшәячәк барлык кешеләрдән үтенеп, ялварып сорыйм: Ольга Ивановна Щапова турында язган бу юлларымны саклагыз". Сөргенгә куылган ике кешенең багланышларына характеристика булу өстенә, Ольга Ивановна турындагы бу мәкалә — Щаповның хатын-кыз мәсьәләсенә карашын белү өчен дә әһәмиятле. Байтак кына бүтән мәкаләләрендә дә Щапов — Россиядәге хатын-кызлар хәлен яктырта һәм бу мәсьәләдә дә алдынгы позициядә тора. Аның түбәндәге сүзләре шуны күрсәтәләр: — „Россияне коткару эше социаль хәлгә реформа ясауга, халык хезмәтен рәткә салуга һәм халыкның дөньяга карашында реформа үткәрүгә бәйләнгән. Бу эш барлык халыкка табигый-фәнни белемнәр бирү, барлык яшь эшче буыннарны тәрбияләү һәм шулай ук хатын-кызны азатлыкка чыгару юлы белән башкарылырга тиеш. Чөнки тарих эшчеләр хезмәте белән хатын-кыз хезмәте мәсьәләсен тикмәскә генә синхроник мәсьәлә ясамады һәм аларның хәл ителүен дә ниндидер бер срокка хәтле тикмәскә генә кичектермәде... Хатын-кызларның җәмагатьчелек эшчәнлеге юлына чыгулары белән, бу — хәзер әле бик күпләргә хыял булып күренә... Ләкин эшче союзлар һәм артельләр тарафыннан эзләнелеп киленгән... социаль кооператив хезмәт ассоциациясе үсеп китәр, чәчәк атар".

Хатынының үлеме Щаповка соңгы удар булды һәм шуннан соң ул тормышын төзәтеп җибәрә алмады. Ешрак эчә башлады, уйлау сәләте дә зәгыйфләнә барды. Ул мәкаләләр язарга да тотынып карады, ләкин инде аларны журнал редакцияләре кабул итмәделәр. Соңгы елларда язган хатлары аңар кичерергә туры килгән трагедияне ачып салалар: „Китапсыз яшәү — җанга үлем. Ә җидди китапларны — фәлсәфә, табигый-фәнни һәм социология китапларын укырга сусау шундый көчле, шундый үткен һәм зарыктыргыч. Китаплар, китаплар!.. Бер яхшы китап укысаң ул синең башыңда биш яңа китап тудыра ала". Бу елларны ул фәкать сөргендәге политиклар белән генә аралаша. Петербургга җибәргән

бер хатында ул: „Болар белән ичмасам сагышлы йөрәкне бушатып була. Алар барсы да — ярлы ябагай. Аларның кайберләре каторгадан, Александр заводыннан килгәннәр“ — дип яза.

Соңгы вакытта инде ул аксап, картлар төсле чайкалып, бик акрын гына атлап йөри, аның күзләре дә шул чаклы көчсезләнә, хәтта ул иң эре хәрефле үз язуын да көчкә таный.

Афанасий Прокофьевич 1876 нчы елны 27 февральдә, 45 яшендә, котчыккыч ярлы тормыш шартларында чахоткадан үлә. Газеталарда аның үлеме турында язуны тыялар. Аның табуты артыннан берничә кеше генә озата бара. Петербургда Щаповның үлеме турындагы хәбәрне шактый озак вакыт үткәч, хосусый хаттан укып кына беләләр.

„Восточное обозрение“ газетасының 1876 нчы елгы бер номерында, авторының исме куелмыйча гына басылган бер мәкаләдә Щапов искә алына:

„Гади кешеләр белән, хәтта иң соңгы лакей белән дә шундый якын, шундый бирелгән туганлык мөнәсәбәтендә торган Щапов төсле бүтән бер кеше барлыгын белмим. Аның уенча, кешеләрнең ике сорты гына чын ихтирамга лаек. Берсе — белем аркылы үз интересларының халык интересы белән чын туганлык бердәмлеген һәм бу мәсьәләдә эш белән сүзнең аерылмаслык бәйләнешен аңлау дәрәҗәсенә күтәрелгән югары белемле кешеләр. Икенчесе — үзенең бозылмаганлыгы һәм табигый сизгерлеге буенча шул ук сыйфатларга ия булган халык“.

„Бурса, семинария һәм академия тоткыны, Петербург хәрби госпиталендәге арестантлар отделениесенең тоткыны, Казаннан Петербургка, Петербургтан Иркутскига, Иркутскидан Омскига һәм кире юлны тоткынлыкта үткәрүче, Иркутскида тоткын булып яшәүче һәм 12 ел буенча кайгы һәм ярлылык белән акрынлап үтерелүче“[1] — менә А. П. Щаповның тормыш юлы шундый. Бу гомерлек тоткын булып яшәү — аның гыйлми эшләренә дә үзенең авыр эзен салды. Щапов җидди нигезләнгән фән мәктәбе тудыра алмады, ләкин аның табигый таланты тарихи процессларны аңлатуда, шуларга бәя бирүдә күп

[1] Шашков.

кенә яңа һәм якты фикерләр калдырды. Чынлык эзләү юлында ул үзенең дөньяга карашын берничә тапкыр яңа баштан карап, кешелек тарихын аңлауда материалистик карашка басты. Маркснын замандашы булган бу галим әле аның идеяләрен бер бөтен үзенә аерым теория итеп күрсәтә белмәсә дә, эпоханы сизүдә искиткеч сәләткә ия булган Щапов Марксны — „Кешелекнең бөек юлбашчысы һәм остазы" дип атый.

Демократ тарихчы А. П. Щапов — безгә, социалистик эпоха кешеләренә үзенең тирән патриотизмы белән, халыкка мәхәббәте белән һәм безнең социалистик илебездә миллионнарча хезмәт ияләренең иректә тормышы төсендә барлыкка китерелгән идеяләре белән, кешелек дөньясын коллыктан һәм изелүдән азат итү турындагы якты идеяләре белән якын тора.

*Проф. В. Н. Терновский.*

*Татарчалаштыручысы: Кави Нәҗми.*